**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карары**

ав. Чубар-Абдул № 114 " 15" октябрь 2018 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 17.05.2018 № 100 карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 47 статьясындагы 2 өлеше нигезендә

Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 17.05.2018 № 100 карарына үзгәреш кертергә, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«4. Әлеге карар 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла. "

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: Н.Ә. Фәтхетдинов